**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №107-55 “20” сентябрь 2018 ел

Сарлы авылы җирлеге биләмәсендә үзара салым җыю һәм куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Сарлы авыл җирлеге Уставының 12 маддәсе, Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Сарлы авыл җирлеге Советының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 106-54 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезендә,

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарлы авыл җирлеге биләмәсендә үзара салым җыю һәм куллану буенча 18 ноябрь 2018 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Сарлы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме? Үзара салым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (Сарлы, Сөендек авылларында юлларны төзекләндерү);
2) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (Сарлы, Сөендек, Бүләк авылларында юлларны кардан чистарту);
3) мәдәният оешмаларына җирлек халкының ялын оештыру һәм тәэмин итү өчен шартлар тудыру (“Сабантуй” бәйрәмен оештыру һәм уздыру);

ӘЙЕ ЮК”

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә: http://aznakayevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис: М.Р.Шарипов